СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 г. Заинск № 245

**«Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләргә һәм эшчеләргә хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Советының «Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләргә һәм эшчеләргә хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы карары белән расланган (Зәй муниципаль районы Советының 2020 елның 27 августындагы 555, 2021 елның 27 декабрендәге 192, 2022 елның 29 сентябрендәге 235 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләргә һәм эшчеләргә хезмәт хакы түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктта «11958 сум» сүзләрен «12688 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.3 пунктның 3 пунктчасында «ике процент» сүзләрен «15 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П.С.Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**